ГЛАВА
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

27.05.2020 № 29-р

п.г.т.Алексеевское

**Алексеевск муниципаль районының җирле үзидарә органнарында халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча халык дружинасының район штабы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча 2020 елның 30 апреленнән нәтиҗәне карап, коррупциячел факторларны бетерү максатларында:

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башлыгының «Халык дружинасының район штабын төзү турында» 2015 елның 27 апрелендәге 69-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында халык дружиналарының эшчәнлеген координацияләү буенча район штабы турындагы нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр кертергә:

- 5.11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.11. Халык дружинасы штабы карары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм утырышта рәислек итүче һәм халык дружинасы штабы секретаре тарафыннан имзалана. Халык дружинасы штабы әгъзаларының аерым фикере язмача рәвештә бәян ителә һәм халык дружинасы штабы карарына кушып куела. Беркетмә штаб секретаре тарафыннан штаб утырышын уздырганнан соң 3 көн эчендә председательлек итүче тарафыннан рәсмиләштерелә.».

2. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы башлыгы урынбасары Г.В. Беловага йөкләргә.

**Муниципаль район башлыгы** **С.А. Демидов**